ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 28 маендагы** **Чистай шәһәре** **№ 279**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 5 февралендәге “Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында”гы 74 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 2018 елның 5 февралендәге 74 номерлы карарына Чистай шәһәр прокурорының 2020 елның 22 маендагы 02-08-02-2020 номерлы таләбен карап, “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы “Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында”гы 9 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. “Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында”гы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 5 февралендәге 74 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары О.В. Купцовага йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов